ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 630 2017 елның 11 октябре

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 14 июлендәге 443 номерлы «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларының туклануын оештыру системасына күчүе турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Гомуми белем бирү оешмалары тарафыннан туклануны оештыру өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәтне муниципаль контрактның гамәлдә булу срогына хезмәт күрсәтүне потенциаль башкаручыга бушлай тапшыру белән бәйле рәвештә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 14 июлендәге 443 номерлы «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларының туклануын оештыру системасына күчүе турында» карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Карарның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләренә, төзелгән муниципаль контрактлар нигезендә, ашханә бүлмәләрен, ашханә җиһазларын, ашханә мебельләрен, кухня инвентарен, савыт-сабаны туклануны оештыру буенча хезмәт күрсәтүне үтәүчегә түләүсез тапшыруны тәэмин итәргә.».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Р. Фәретдиновка йөкләргә.

А.Г. Сәйфетдинов